# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 28 декабрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 13 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ статья өстәргә:
"$13^1$ статья. **Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яше**

1. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яше – 60 яшь. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте срогы аның ризалыгы белән яллаучы вәкиленең карары буенча озайтылырга мөмкин, әмма 65 яшьтән дә артыкка түгел, ә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка ярдәм итү өчен гамәлгә куелган "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә – күрсәтелгән затның вәкаләтләр чоры тәмамланганчыга кадәр.

2. Дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткәч, яллаучы вәкиле карары буенча һәм гражданның ризалыгы белән ул дәүләт

органында дәүләт хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфада вакытлы хезмәт шартнамәсе шартларында эшләвен дәвам итәргә мөмкин.";

4) 32 статьяда:

а) 1 өлешнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10) 2001 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы районнарындагы һәм шәһәрләрендәге идарәләре җитәкчеләре, белгечләре вазыйфаларын.";

б) 2 өлешнең 2 пунктында "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфалары реестрында каралмаган" сүзләрен "Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт вазыйфалары реестрында каралмаган" сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлешнең "б" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"б) 2001 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы районнарындагы һәм шәһәрләрендәге идарәләре җитәкчеләрен, белгечләрен.";

5) 45 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Дәүләт хезмәте стажы 15 ел булганда, дәүләт хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата тулы кеременең 20 проценты күләмендә билгеләнә. Дәүләт хезмәте стажының 15 елдан артып киткән һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия айлык акчалата тулы keremnән 3 процентка арттырыла. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата тулы кеременең 50 процентыннан артыграк була алмый.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме картлык буенча хезмәт пенсиясе иминият өлешенең "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнеп беркетелгән база күләменнән кимрәк була алмый.";

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия исәпләп чыгарганда һәм билгеләгәндә алына торган айлык акчалата тулы керем составына вазыйфаи оклад, класслы чин өчен оклад, шулай ук вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен, дәүләт хезмәтендәге аерым шартлар өчен, профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәлмәләр кертелә, аларның күләме дәүләт хезмәткәре эштән азат ителгән көнгә булган күләмдә билгеләнә. Бу чакта вазыйфаи окладка дәүләт хезмәтендәге аерым шартлар өчен айлык өстәлмә дәүләт хезмәткәре эштән азат ителгән көнгә кадәр кимендә алты ай алданрак билгеләнгән күләмдә кертелә.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләп чыгарганда әлеге өлеш нигезендә исәпкә алына торган айлык түләүләр айлык акчалата тулы керем составына бары тик алар дәүләт хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча фактта алынганда гына кертеләләр.";

в) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 12 өлешнең өченче һәм дүртенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 28 декабрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) әлеге Закон нигезендә билгеләнә торган айлык акчалата керемнән һәм айлык акчалата кызыксындыру түләвеннән тора торган айлык акчалата тулы керем;";

2) 13 статьяда:

а) 3 өлешнең 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасында кимендә тулы бер срок узгач вәкаләтләрен үтәүне туктаткан зат вафат булган очракта, аның гаиләсенә Татарстан Республикасы Президентының айлык акчалата кеременең уникеләтелгән күләмендә бер мәртәбә пособие түләнә. Күрсәтелгән пособиене түләү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән билгеләнә.";

3) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ статья өстәргә:

"$13^1$ статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә дәүләт гарантияләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затларга – шул вазыйфада кимендә тулы бер срок узгач, ә инвалидлык буенча пенсия билгеләнгәндә, вәкаләтләр үтәү срогына бәйсез рәвештә:

1) пенсиягә, Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасы буенча айлык акчалата тулы керемнән чыгып, әлеге Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмдә өстәмә билгеләнә;

2) били торган вазыйфа буенча айлык акчалата тулы керемнең унлатылган күләмендә бер мәртәбә акчалата тулы керем түләнә;

3) Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә транспорт хезмәте, телефон элемтәсе хезмәте күрсәтелә;

4) аэропортларның һәм аэровокзалларның, тимер юл вокзалларының һәм станцияләренең, диңгез һәм елга вокзалларының (портларының) рәсми затлар һәм

делегацияләр өчен булган залларыннан файдалану чыгымнары Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә каплана.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затларның гаилә әгъзаларына әлеге Законның 13 статьясындагы $3^1$ (Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасы буенча айлык акчалата керемнән чыгып), 4 һәм 5 өлешләрендә каралган гарантияләр бирелә.";

4) 15 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затлар пенсиясенә өстәмә түбәндәгечә билгеләнә: дәүләт вазыйфасын бер елдан өч елга кадәр биләгәндә – тиешле вазыйфа буенча исәпләнгән айлык акчалата тулы керемнең 45 проценты күләмендә, өч елдан артык биләгәндә – 65 проценты күләмендә. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын кимендә 15 ел биләгән йә күрсәтелгән вазыйфаларны өч елдан артыграк биләгән һәм дәүләт хезмәте стажы барлыгы кимендә 15 ел булган затлар пенсиясенә өстәмә Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасы буенча исәпләнгән айлык акчалата тулы керемнең 70 проценты күләмендә билгеләнә.

Пенсиягә өстәмә күләме картлык буенча хезмәт пенсиясе иминият өлешенең "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнеп беркетелгән база күләменнән кимрәк була алмый.";

б) 3 өлештә "исәп-хисап күләмен" сүзләрен "айлык исәп-хисап күләмен" сүзләренә алмаштырырга;

5) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын элек биләгән затларны пенсия белән тәэмин итү үзенчәлекләре**

1. Әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, шушы Закон нигезендә пенсиягә өстәмә хокукына 2005 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук аларга тиңләштерелгән вазыйфаларны, шул исәптән Татарстан Республикасының конституциячел дәүләт вазыйфаларын, Татарстан АССР, Татарстан ССР дәүләт вазыйфаларын, биләгән затлар ия була. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларына тиңләштерелгән вазыйфаларның җыелма исемлеге Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең республика органнарында дәүләт вазыйфаларын һәм аларга тиңләштерелгән вазыйфаларны биләгән затлар пенсиясенә өстәмә охшаш яисә аңа тиңләштерелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы буенча исәпләнә торган айлык акчалата тулы керемгә карата билгеләнә һәм исәпләп чыгарыла, айлык акчалата тулы керем Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре буенча хезмәт өчен түләү төркемнәрен исәпкә алып билгеләнә.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларның, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән затлардан тыш, пенсиясенә өстәмә тиешле дәүләт вазыйфасына тиңләштерелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча айлык акчалата тулы керемгә карата билгеләнә һәм исәпләп чыгарыла. Вазыйфаи окладка өстәлмәләр күрсәтелгән затлар пенсиясенә өстәмә билгеләгәндә һәм исәпләп чыгарганда алына торган айлык акчалата тулы керем составына бары тик аларны шул затлар тиешле вазыйфаларны биләгән чорда алган булсалар гына кертеләләр.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вазыйфаларның Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларына, дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына туры китерү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.";

б) 19 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда, муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кеременең 20 проценты күләмендә билгеләнә. Муниципаль хезмәт стажының 15 елдан артып киткән һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия айлык акчалата тулы керемнән 3 процентка арттырыла. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кеременең 50 процентыннан артыграк була алмый.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме картлык буенча хезмәт пенсиясе иминият өлешенең "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнеп беркетелгән база күләменнән кимрәк була алмый.";

б) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча тиешле еллар эшләгән өчен пенсиянең максималь күләмен исәпләп чыгарганда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи окладның максималь күләме кулланыла (әгәр вазыйфаи оклад максималь һәм минималь күләмдә булса), ә стаж озынлыгы һәм айлык түләүләр тиешле еллар өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәр өчен әлеге Закон нигезендә билгеләнгән шундый ук күләмнәрдә исәпкә алына.";

в) 6 өлешнең өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

г) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия исәпләп чыгарганда һәм билгеләгәндә алына торган айлык акчалата тулы керем составына вазыйфаи оклад һәм вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен, муниципаль хезмәттәге аерым шартлар өчен, классны чин өчен, профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәлмәләр керә. Бу чакта вазыйфаи окладка муниципаль хезмәттәге аерым шартлар өчен айлык өстәлмә муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнгә кадәр кимендә алты ай алданрак билгеләнгән күләмдә кертелә.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләп чыгарганда әлеге өлеш нигезендә исәпкә алына торган айлык түләүләр айлык акчалата тулы керем составына бары тик алар муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча фактта алынганда гына кертеләләр.";

д) 13 өлешнең өченче һәм дүртенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) 23 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфалары реестрында каралмаган" сүзләрен "Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт вазыйфалары реестрында каралмаган" сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләгән затның пенсиясенә өстәмә, пенсиягә өстәмә билгеләү өчен стажы 15 ел булганда, тиешле муниципаль вазыйфа буенча айлык акчалата керемнең 20 проценты күләмендә билгеләнә. 15 елдан артып киткән һәр тулы ел өчен пенсиягә өстәмә айлык акчалата тулы керемнән 3 процентка арттырыла. Шул ук вакытта пенсиягә өстәмә күләме даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләгән затның айлык акчалата тулы кеременең 50 процентыннан артыграк була алмый.";

2) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Пенсиягә өстәмә исәпләп чыгарганда һәм билгеләгәндә алына торган айлык акчалата тулы керем составына әлеге Закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнгән айлык акчалата керем һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве керә.".

**5 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктларыннан тыш, 2011 елның 1 июленнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктлары ул рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**6 статья**

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затларга тиешле еллар эшләгән өчен әлеге Закон үз көченә кергәнче билгеләнгән пенсияләр (пенсиягә өстәмәләр) "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 һәм 46 статьялары (әлеге Закон редакциясендә), "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 16 статьялары (әлеге Закон редакциясендә), "Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы (әлеге Закон редакциясендә), "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы (әлеге Закон редакциясендә), шулай ук әлеге Законның 7 статьясы нигезендә аларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсия (пенсиягә өстәмә) билгеләү юлы белән яңадан каралырга тиеш. Шул ук вакытта, әгәр тиешле еллар эшләгән өчен әлеге Закон үз көченә кергәнче алына торган пенсия (пенсиягә өстәмә) күләме тиешле еллар эшләгән өчен күрсәтелгән Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән пенсия (пенсиягә өстәмә) күләменнән артып китсә, гражданның тиешле еллар эшләгән өчен пенсиясенең (пенсиягә өстәмәсенең) югарырак күләмдәгесе сакланып кала.

**7 статья**

1. 2006 елның 1 гыйнварына кадәр эштән азат ителгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләгәндә, айлык акчалата тулы керем составына вазыйфаи оклад, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә 2006 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган хезмәт өчен түләү шартларында каралган вазыйфаи окладка өстәлмәләр, эш нәтиҗәләре буенча премияләр һәм матди ярдәм кертелә. Шул ук вакытта эш нәтиҗәләре буенча премияләр вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә исәпкә алына, ә тиешле еллар өчен пенсия билгеләгәндә кертелә торган матди ярдәм ул сумманың 1/12 күләмендә исәпкә алына.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләп чыгарганда әлеге өлеш нигезендә исәпкә алына торган түләүләр айлык акчалата тулы керем составына бары тик алар Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча фактта алынганда гына кертеләләр.

2. 2006 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затлар һәм шуларга тиңләштерелгән затлар пенсиясенә өстәмә күләме 1,5 коэффициентын кулланып исәпләнә.

**8 статья**

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары өч ай эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 24-ТРЗ